# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Оешмалар мөлкәтенә салым турында" 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлешне өстәргә:

"$1^1$. 0,01 процент күләмендәге салым ставкасы 2011 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 1 июленә кадәр эксплуатациягә кертелгән, техник документация буенча машина урыны саны кимендә 150 берәмлек булган автомототранспорт чараларын куеп торуның күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларына куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәте күрсәтүләр өчен турыдан-туры файдаланыла торган мөлкәткә билгеләнә.";

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4) 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы $1^1$ өлешен.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2011 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 8 мае
№ 16-ТРЗ